ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.09.2022 г. Заинск № 496

**«2025 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы муниципаль планын раслау турында»**

«Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль законны, «Татарстан Республикасында торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм фонды турында» 2007 елның 14 ноябрендәге ПУ-611 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указын, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны раслау турында" 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планын раслау турында» 2019 елның 27 декабрендәге 1220 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. 2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы муниципаль планын, кушымтаны яңа редакциядә бәян итеп, расларга.

2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында (http://zainsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Н. Кулагина
(85558) 7-08-18

Юрист

Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетның
2022 елның «26» 09
496 номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

2023-2025 елларда Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы муниципаль планы

## I. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге 2023-2025 елларда Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы муниципаль планы (алга таба - кыска сроклы план, региональ программа) Россия Федерациясе Торак кодексы, «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - Федераль закон), «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә региональ программаны тормышка ашыру, күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау срокларын, күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча планлаштырылган хезмәт төрләрен һәм (яки) эшләрне төгәлләштерү, дәүләт ярдәме төрләрен һәм күләмнәрен билгеләү, капиталь ремонт үткәрүгә муниципаль ярдәм күрсәтү максатларында эшләнде.

## II. Кыска сроклы планның төп максатлары һәм бурычлары

Кыска сроклы планның төп максатлары:

Зәй муниципаль районында торак фондын саклау, торгызу һәм аның сыйфатын яхшырту;

гражданнарның яшәве өчен куркынычсыз һәм уңайлы шартлар булдыру;

күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауда дәүләт ярдәме, муниципаль ярдәм күрсәтү.

Кыска сроклы планның төп бурычлары:

халык белән актив агитация-аңлату эшләре алып бару;

кыска сроклы планны үтәүчеләрне сайлап алуда үтә күренмәле һәм ачык процедураларны эшләү һәм тәэмин итү;

озакка чыдам материаллар һәм ресурсларны саклый торган технологияләр кулланып, капиталь ремонт үткәргәндә нәтиҗәле техник чаралар куллану һәм комплекслылыкны тәэмин итү.

Кыска сроклы планны гамәлгә ашыру вакыты – 2023-2025 еллар.

Кыска сроклы планны гамәлгә ашыру гомуми мәйданы 202812 мең кв.метр булган 49 күпфатирлы йортта 7045 гражданга имин һәм уңайлы яшәү шартларын тәэмин итәргә тиеш.

Зәй муниципаль районы буенча әлеге кыска сроклы планны үтәү буенча планлаштырылган күрсәткечләр әлеге кыска сроклы планга 3нче кушымтада бирелә.

## III. Кыска сроклы планны үтәүдә катнашучы муниципаль берәмлекләр исемлеге

Кыска сроклы планны үтәүдә катнашучы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре исемлеге Зәй муниципаль районы территориясендә түбәндәгеләрне исәпкә алып формалаштырылды:

а) Федераль законның 14 статьясында каралган финанс ярдәме күрсәтү шартлары үтәлүне;

б) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы (еллык) планнары дәүләт торак күзәтчелеге органнары белән раслануны һәм килештерелүне.

Кыска вакытлы планны гамәлгә ашыруда катнаша: Зәй шәһәре.

## IV. 2023-2025 елларда күпфатирлы йортларда капиталь ремонт үткәрү күләмнәре

| 2023 -2025 елларда планлаштырылган күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эшләр күләме | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 2023 | 2024 | 2025 |
| 1. Түбәне ремонтлау, шул исәптән вентиляциясез түбәне вентиляцияле итеп үзгәртү, түбәгә чыгу җайланмалары көйләү | кв.м. | 7128,28 | 5491,82 | 5359,45 |
| 2. Йорт эчендәге электр, газ, су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу системаларын ремонтлау һәм алмаштыру, шул исәптән торак биналарда урнашкан җылыту элементларын, шулай ук йорт эчендәге инженерлык системаларында урнашкан механик, электр,санитар-техник җиһазларны ремонтлау яки алыштыру , шул исәптән: | мең метр | 11054,45 | 14136,69 | 5620,12 |
| 2.1электр белән тәэмин итү | кв.м. | 197,65 | 2794,16 | 1829,31 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2.2 җылылык белән тәэмин итү | метр озынлык. | 1780,38 | 7976,56 | 1938,06 |
| 2.3 су белән тәэмин итү | метр озынлык. | 6958,78 | 2594,32 | 1248,34 |
| 2.4 су чыгару | метр озынлык. | 2117,64 | 771,65 | 604,41 |
| 3. Коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен (җылылык энергиясе, кайнар һәм салкын су, электр энергиясе, газ бирү) кирәкле ресурсларны куллануны исәпкә алу буенча күмәк (гомумйорт) приборлар урнаштыру. | данә | 0 | 0 | 0 |
| 4. Ресурсларны куллануны җайга салу узелларын һәм идарә узелларын урнаштыру | данә | 0 | 0 | 0 |
| 5. Файдалану өчен яраксыз дип табылган лифт җиһазларын алмаштыру | дан | 3 | 2 | 3 |
| 6. Лифт шахталарын ремонтлау | данә | 0 | 0 | 0 |
| 7. Күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә караган подвал бүлмәләрен ремонтлау | мең кв.метр | 0 | 0 | 0 |
| 8. Фасад ремонты | кв.м. | 0 | 0 | 1423 |
| 9. Фасадны җылыту | мең кв.метр | 6675,63 | 14213,63 | 0 |
| 10. Күпфатирлы йортның фундаментын ремонтлау | мең куб.метр | 0 | 0 | 0 |
| 11. Күпфатирлы йортка энергетик яктан тикшерүләр үткәрү | данә | 0 | 0 | 0 |
| 12. Күп фатирлы йортларны техник инвентаризацияләү буенча эшләр башкару һәм техник паспортлар әзерләү | данә | 0 | 0 | 0 |
| 13. Күпфатирлы йортта подъездларны ремонтлау | мең кв.метр | 70 | 0 | 0 |
| 14. Күпфатирлы йортның янгыннан саклау системасын ремонтлау | мең кв.метр | 0 | 0 | 0 |
| 15. Төзелеш контролен тормышка ашыру | данә | 20 | 16 | 13 |
| 16. 16. Проект документларына дәүләт экспертизасын эшләү һәм үткәрү | данә | 20 | 16 | 13 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 17. Күпфатирлы йортларда гомуми милек составында конструкцияләрне һәм инженерлык системаларын капиталь ремонтлау эшләрен башкарганда технологик һәм конструктив үзенчәлекләр, ремонтлана торган (алыштырыла торган) конструкцияләр һәм инженерлык системалары аркасында демонтажланган яки җимерелгән милек өлешләрен торгызу, шулай ук ремонт эшләре тәмамланганнан соң төзекләндерү | данә | 0 | 0 | 0 |

Күпфатирлы йортларда капиталь ремонт үткәрү күләмнәре әлеге кыска сроклы планга 2 нче кушымтада бирелә.

## V. Күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлауны өлешләп финанслау күләмнәрен нигезләү.

Планга кертелгән күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлауны өлешләп финанслау күләмнәрен нигезләү Федераль законның 18 статьясындагы 3 өлеше нигезендә, кыска сроклы планга кертелгән күпфатирлы йортлар исемлегеннән чыгып башкарыла.

## VI. Ресурслар белән тәэмин итү

Кыска сроклы планны финанслау чыганаклары булып Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет һәм күпфатирлы йорттагы милекчеләр средстволары тора.

2023 – 2025 елларда кыска сроклы план чараларын финанслауның гомуми күләме, шул исәптән:

- Татарстан Республикасы бюджетыннан – 44 952 816,76 сум;
- Зәй муниципаль районы бюджетыннан – 47 952 000 сум;
- торак милекчеләреннән – 127 024 229,67 сум.

2023-2025 елларда
күп фатирлы йортларны капиталь ремонтлауга финанс чаралары күләме

| № п/п | Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Сумма, 2023 елга млн. сумнарда. | Сумма, 2024 елга млн. сумнарда. | Сумма, 2025 елга млн. сумнарда. |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Түбәне ремонтлау, шул исәптән вентиляциясез түбәне вентиляцияле итеп үзгәртү, түбәгә чыгу җайланмалары көйләү | 32,26 | 19,37 | 36,27 |
| 2. | Йорт эчендәге электр, газ, су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу системаларын ремонтлау һәм алыштыру, шул исәптән торак биналарда урнашкан җылыту элементларын, шулай ук, йорт эчендәге инженерлык системаларында урнашкан механик, электр, санитар-техник җиһазларны ремонтлау һәм алыштыру, шул исәптән: | 22,59 | 32,73 | 22,41 |
| 2.1 | электр белән тәэмин итү | 1,5 | 4,5 | 6,5 |
| 2.2 | җылылык белән тәэмин итү | 4,76 | 11,34 | 6,3 |
| 2.3 | су белән тәэмин итү | 10,52 | 12,19 | 6,45 |
| 2.4 | су чыгару | 5,81 | 4,7 | 3,16 |
| 3. | Индивидуаль җылыту пунктлары (ИТП) урнаштыру һәм алмаштыру | 0 | 0 | 0 |
| 4. | Коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен (җылылык энергиясе, кайнар һәм салкын су, электр энергиясе, газ бирү) кирәкле ресурсларны куллануны исәпкә алу буенча күмәк (гомумйорт) приборлар урнаштыру | 0 | 0 | 0 |
| 4. | Ресурсларны куллануны җайга салу узелларын һәм идарә узелларын урнаштыру | 0 | 0 | 0 |
| 5. | Файдалану өчен яраксыз дип табылган лифт җиһазларын алмаштыру | 4,61 | 3,9 | 7,1 |
| 6. | Лифт шахталарын ремонтлау | 0 | 0 | 0 |
| 7. | Күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә караган подвал биналарын ремонтлау | 0 | 0 | 0 |
| 8. | Фасад ремонты | 0 | 0 | 2,79 |
| 9. | Фасадны җылыту | 7,82 | 11,4 | 0 |
| 10. | Күпфатирлы йортның фундаментын ремонтлау | 0 | 1,3 | 0 |
| 11. | Күпфатирлы йортка энергетика тикшерүләре үткәрү | 0 | 0 | 0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 12. | Күп фатирлы йортларны техник инвентаризацияләү буенча эшләр башкару һәм техник паспортлар әзерләү | 0 | 0 | 0 |
| 13. | Күпфатирлы йорт подъездларын ремонтлау | 0,65 | 0 | 0 |
| 14. | Күпфатирлы йортның янгыннан саклау системасын ремонтлау | 0 | 0 | 0 |
| 15. | Проект документларына дәүләт экспертизасын эшләү һәм үткәрү | 4,1 | 3,7 | 3,83 |
| 16. | Проект документларына дәүләт экспертизасын эшләү һәм үткәрү | 0 | 0 | 0 |
| | | | | |
| 17. | Төзелеш контролен гамәлгә ашыру | 1,02 | 1,03 | 1,03 |
| 18. | Күпфатирлы йортларда гомуми милек составында конструкцияләрне һәм инженерлык системаларын капиталь ремонтлау эшләрен башкарганда технологик һәм конструктив үзенчәлекләр, ремонтлана торган (алыштырыла торган) конструкцияләр һәм инженерлык системалары аркасында демонтажланган яки җимерелгән милек өлешләрен торгызу, шулай ук ремонт эшләре тәмамланганнан соң төзекләндерү | 0 | 0 | 0 |
| 19. | Установка узлов учета Ресурсларны куллануны җайга салу узелларын урнаштыру (бары тик ТСЖ, ТК, ТТК яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары яисә күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре акчалары хисабына гына, шул ук вакытта ресурсларны куллануны җайга салу төеннәрен урнаштыруны финанслау 2014 елдан 2019 елга кадәр кыска сроклы планнар һәм төзелгән шартнамәләр нигезендә) гамәлгә ашырыла | 0 | 0 | 0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 20. | Аларны урнаштыру 2017 елның 1 июненә кадәр гамәлгә ашырылган күпфатирлы йортларда коммуналь ресурсларны куллануны исәпкә алу буенча күмәк (гомумйорт) приборларны урнаштыру (алмаштыру) (бары тик ТСЖ, ТК, ТТК һәм башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары яки күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре хисабына гына урнаштыру (алмаштыру)) | 0 | 0 | 0 |
| | Барысы: | **73,05** | **73,43** | **73,43** |

Капиталь ремонт үткәрүнең бәясен күрсәтеп, шул исәптән Фонд акчалары исәбеннән, күпфатирлы йортлар исемлеге әлеге кыска вакытлы планга 1 нче кушымтада китерелә.

## VII. Капиталь ремонт буенча эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең иң чик бәясе

2023-2025 елларга күпфатирлы йортларда биналарның гомуми мәйданының 1 кв. метрына исәпләгәндә хезмәтләрнең һәм (яки) капиталь ремонт эшләренең чик бәясе 14 мең сум тәшкил итә.

Капиталь ремонт буенча хезмәтләрнең һәм (яки) эшләрнең чик бәясеннән артып китү, шулай ук хезмәт күрсәтүләргә һәм (яки) кыска сроклы планда каралмаган эшләргә түләү, капиталь ремонт өчен взносның минималь күләменнән артыграк түләнә торган күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләре хисабына гамәлгә ашырыла.

## VIII. Кыска сроклы планны гамәлгә ашыру механизмы

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты:**

күрсәтелгән вакыт чикләрендә өч елга муниципаль программаны гамәлгә ашыруның муниципаль кыска вакытлы планнарын формалаштыра һәм министрлыкка җибәрә;

министрлыкка муниципаль берәмлек тарафыннан финанс ярдәме күрсәтү шартларын үтәүне раслаучы норматив хокукый актларның күчермәләрен һәм башка документларны тапшыра;

торак законнары нигезендә, кыска вакытлы планда билгеләнгән күләмдә капиталь ремонт эшләрен финанслашуга җирле бюджет акчаларын күчерә;

региональ оператор белән килешү (шартнамә) нигезендә күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләргә техник заказ бирүче функцияләрен гамәлгә ашыра;

күпфатирлы йортка капиталь ремонт ясау чыгымнарының расланган сметасында каралмаган акчалардан файдалану, шулай ук аннан артып киткән очраклардан тыш, башкарылган эшләр актларын, капиталь ремонт эшләрен кабул итү актларын килештерә;

күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау буенча эшләр башкаруга бүлеп бирелгән акчаларның максатчан кулланылышын контрольдә тота;

министрлык тарафыннан билгеләнгән тәртиптә тиешле муниципаль берәмлек буенча кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру максатларында мәгълүматлар базасын төзи һәм аны актуаль хәлдә тота (шул исәптән күпфатирлы йортлардагы торак һәм торак булмаган урыннар мәйданнары буенча белешмәләр);

министрлыкка һәм кыска вакытлы планны башка башкаручыларга дәүләт корпорациясе - торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм фондына хисапларны формалаштыру өчен кирәкле документларны һәм белешмәләрне тапшыра.

**ТМШ, ТТК, ИК, идарәче оешмалар:**

тикшерү актларын, капиталь ремонт буенча эшләр күләменә дефект ведомостьларын килештерәләр;

региональ оператор белән килешү (шартнамә) төзиләр, алар нигезендә ТСЖ, ТТК, ИК, ИО түләү документларын формалаштыралар һәм айлык түләүләрне тәэмин итәләр, региональ оператор счетына капиталь ремонт кертемнәре буенча милекчеләрнең түләүләре, шулай ук капиталь ремонт һәм пеня кертемнәрен түләү буенча бурычларны түләтү чараларын күрәләр;

проект документациясен килештерүне тәэмин итәләр;

Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә милекчеләргә капиталь ремонт башлану срогы, хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең кирәкле исемлеге һәм күләме, аларның бәясе, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны финанслау тәртибе һәм чыганаклары турында тәкъдимнәрне һәм капиталь ремонт үткәрүгә бәйле башка тәкъдимнәрне җиткерәләр.

күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау мәсьәләләре буенча милекчеләр җыелышларын оештыралар;

капиталь ремонт объектларына кертүне гамәлгә ашыралар;

күпфатирлы йортларда капиталь ремонтның үз вакытында һәм сыйфатлы башкарылуын контрольдә тоталар, шулай ук капиталь ремонттан соң күпфатирлы йортларны файдалануга кабул итүдә капиталь ремонт тәмамланган объектларны тикшерү актларына һәм файдалануга тапшыру актларына кул кую хокукы белән катнашалар;

дефект ведомостьларын, күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау буенча проект-смета һәм башкарма документациядне күпфатирлы йортны һәм аңа керүче инженерлык системаларын авариясез эксплуатацияләүнең билгеләнгән гарантия срогыннан да ким булмаган срокка саклыйлар.

Биналарның милекчеләре:

тикшерү актларын, капиталь ремонт буенча эшләр күләменә дефект ведомостьларын килештерәләр;

күпфатирлы йортларда капиталь ремонтның үз вакытында һәм сыйфатлы башкарылуын контрольдә тоту, шулай ук аларны капиталь ремонт тәмамланган объектларны тикшерү актларына һәм файдалануга тапшыру актларына кул кую хокукы белән кабул итүдә катнашалар.

Подряд оешмалары:

кыска сроклы план һәм подряд килешүендә билгеләнгән срокларда күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләрне башкаруны тәэмин итәләр;

КС-2, КС-3 формалары буенча башкарылган эшләр актларын формалаштыралар;

күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләр башкарганда төзелеш контролен гамәлгә ашыралар;

күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләрне сыйфатлы һәм үз вакытында башкару өчен җаваплылык тоталар;

объектны файдалануга тапшыруны тәэмин итәләр;

подряд килешүендә каралган башка эшләрне башкаралар.

**Техник заказчылар:**

проект документларын, шул исәптән сметаны әзерләүне һәм раслауны гамәлгә ашыралар;

күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлаганда төзелеш контролен гамәлгә ашыралар;

башкарылган эшләрне кабул итүдә катнашалар, башкарылган эшләр актларын килештерәләр;

объектны кабул итүдә катнашалар, капиталь ремонт буенча эшләрне кабул итү комиссияләрен төзиләр, күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итү комиссиясе актларын килештерәләр;

күпфатирлы йортлардагы гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләрне сыйфатлы һәм үз вакытында башкару өчен җаваплылык тоталар;

проект оешмасыннан проект документларын кабул итәләр;

күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яки) башкарылган эшләрне кабул итү актына кул куелганнан соң 10 көн эчендә әлеге күпфатирлы йорт белән идарә итүче затка күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау турында документларның күчермәләрен (шул исәптән проект-смета документларының, хезмәт күрсәтү һәм (яки) капиталь ремонт буенча эшләр башкару турында шартнамәләрнең күчермәләрен) һәм капиталь ремонт үткәрүгә бәйле башка документларны (финанс документларыннан тыш) тапшыралар;

законнарда каралган техник заказчының башка функцияләрен гамәлгә ашыралар.

Кыска вакытлы планны планлаштыру, үтәү, контрольдә тоту һәм мониторинглау "Торак фонды мониторингы" бердәм мәгълүмат продуктында гамәлгә ашырыла.

## IX. Подрядчы оешмаларны сайлап алу

Күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) эшләр башкару өчен подрядчы оешмаларны сайлап алу Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 615 нче карары белән расланган нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә төбәк операторы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2023-2025 елларда Зәй муниципаль районы
территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда
гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча региональ
программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы
муниципаль планына 3 нче кушымта

**2023-2025 елларда Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау региональ программасын гамәлгә ашыруның муниципаль кыска сроклы планын үтәү буенча планлаштырылган күрсәткечләр**

| № п/п | Муниципаль берәмлек исеме | КФЙНЫҢ гомуми мәйданы*, кв. метр | Региональ программаны раслау көненә КФЙда теркәлгән кешеләр саны | КФЙ саны | | | | | Капиталь ремонт бәясе | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | I квартал | II квартал | III квартал | IV квартал | Барысы | I квартал | II квартал | III квартал | IV квартал | Барысы |
| | **2023 ел** | | | | | | | | | | | | |
| | Зәй муниципаль районы буенча барысы | 89 649,20 | 3145 | | | | 20 | 20 | | | | 73 055 893,31 | 73 055 893,31 |
| 1 | Зәй муниципаль районы | 89 649,20 | 3145 | | | | 20 | 20 | | | | 73 055 893,31 | 73 055 893,31 |
| | **2024 ел** | | | | | | | | | | | | |
| | Зәй муниципаль районы буенча барысы | 75 268,89 | 2534 | | | | 16 | 16 | | | | 73 436 576,56 | 73 436 576,56 |
| 1 | Зәй муниципаль районы | 75 268,89 | 2534 | | | | 16 | 16 | | | | 73 436 576,56 | 73 436 576,56 |
| | **2025 ел** | | | | | | | | | | | | |
| | Зәй муниципаль районы буенча барысы | 37 894,78 | 1366 | | | | 13 | 13 | | | | 73 436 576,56 | 73 436 576,56 |
| 1 | Зәй муниципаль районы | 37 894,78 | 1366 | | | | 13 | 13 | | | | 73 436 576,56 | 73 436 576,56 |

*МКД - многоквартирный дом